**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**

**(V чакырылыш)**

V чакырылышның чираттан тыш утырышы

# КАРАРЫ

7 июнь 2026 ел № 7

Урыссу ш.т.б.

Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 07.06.2023 № 26 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм гражданнарны шәхсән кабул итү тәртибе һәм сроклары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ санлы, 06.10.2003 № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында», «Россия Федерациясендә гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында»гы 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ санлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында»гы 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 07.06.2023 ел №26 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм гражданнарны шәхсән кабул итү тәртибе һәм сроклары турындагы нигезләмәгә (алга таба - нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 бүлегендәге 2.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Язма мөрәҗәгать җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка кергәннән соң өч көн эчендә мәҗбүри теркәлергә тиеш. Гражданның мөрәҗәгате кергән көн кабул итү мизгеле булып санала.

Гражданнардан мөрәҗәгатьләр бәйрәм яисә ял көннәрендә кергән очракта, аларны теркәү бәйрәм яисә ял көннәреннән соң килә торган эш көнендә башкарыла. Гражданның эштән тыш вакытта мөрәҗәгате җомга көнне кергәндә ул дүшәмбе көнне теркәлә.»;

1.2. Нигезләмәгә 2 нче кушымтаны әлеге карарга кушымта нигезендә редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы Башлыгы -
Татарстан Республикасы
Ютазы Район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин

Р.М. Якупов
(8-85593) 2-42-05

Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы карарына кушымта
«___» ________2026 ел № _____

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ГРАЖДАННАРЫ МӨРӘҖӘГАТЬЛӘРЕ БЕЛӘН ЭШЛӘҮ ТУРЫНДА СТАТИСТИК МӘГЪЛҮМАТЛАР

| № | Районнар һәм шәһәрләр атамасы | Барлыгы мөрәҗәгатьләр керде (язма һәм телдән *** мөрәҗәгатьләр) | | Электрон мөрәҗәгатьләр килде (Интернет кабул итү, электрон почта)**** | | Кире элемтә платформасы аша килде ***** | | Шул исәптән җитәкчелеккә хәбәр ителде ****** | | Контрольгә алынды | | Уңай хәл ителде | | Урынга чыгу белән тикшерелде | | Гражданнар шәхси кабул итүдә кабул ителде | | Шул исәптән җитәкчелек тарафыннан ****** | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 20__ | 20__ | 20__ | 20__ | 20__ | 20__ | 20__ | 20__ | 20__ | 20__ | 20__ | 20__ | 20__ | 20__ | 20__ | 20__ | 20__ | 20__ | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

Искәрмә:

* 01.01.20__-31.12.20__ елга мәгълүмат
** Муниципаль район органнары - Татарстан Республикасы Ютазы район Советы һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты.
*** Телдән мөрәҗәгатьләр: шәхси кабул итү һәм телефон шалтыратулары.
**** Электрон мөрәҗәгатьләр язма мөрәҗәгатьләр санына керә
***** КЭП аша кергән мөрәҗәгатьләр язма мөрәҗәгатьләр санына керә.
****** Җитәкчелек - Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башлыгы һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе.